Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советының егерме сигезенче утырышы

Пановка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

30 октябрь, 2023 ел № 74

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Пановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Пановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 апрелендәге 38 номерлы карары (2023 елның 31 мартындагы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Пановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 23.1 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 24 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «программаны раслаган Башкарма комитет карары нигезендә» сүзләрен «Башкарма комитет билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль программалар чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында федераль законга чираттагы финанс елы башланганчы туры китерелергә тиеш.»;

1.3. 25 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И.Козырев